УДК 373.4 + 811.512.145

***Л.М. Гиниятуллина,***
***М.М. Шәкүрова***

## «ТУГАН ТЕЛ»НЕ УКЫТУНЫҢ ЯҢАЧА ЭЧТӘЛЕГЕ

В статье рассматриваются актуальные проблемы современной методики преподавания предмета «Родной язык». Преподавание родного (татарского) языка предусматривает ознакомление учащихся со спецификой татарского языка и овладение им как средством общения, познания, самореализации и социальной адаптации в поликультурном, полиэтническом мире. Уделяется отдельное внимание обновленному содержанию образовательного процесса и перспективам обучения родному языку.

**Ключевые слова:** родной язык, татарский язык, образовательный процесс, компетенция.

Бүгенге көндә җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләр уку-укыту системасының барлык өлкәләренә дә яңача якын килүне таләп итә. Укыту-тәрбия системасын яңарту ул – үрнәк белем бирү һәм үрнәк эш программаларына нигезләп, инновацион технологияләр, яңа ысуллар, алымнар, чаралар, кулай принциплар эзләү, иң отышлы компетенцияләргә нигезләнү дигән сүз. Бүгенге көндә белем бирү оешмаларының бурычы – хәзерге көн таләпләренә, тормыш ихтыяҗларына җавап бирердәй белемле, тирән фикер йөртүгә сәләтле, актив социаль позициядә торган, креатив, карарларны мөстәкыйль кабул итә белгән иҗади шәхес тәрбияләү.

Татар теле – Россиядә сан ягыннан икенче урында торган, күбесенчә Татарстан Республикасында, шулай ук Россия Федерациясе субъектларында, якын һәм ерак чит илләрдә яшәүче татарларның туган теле. Ул Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр» Законы нигезендә дәүләт телләренең берсе статусына ия.

Федераль белем бирү стандарты һәм югарыда күрсәтелгән документлар нигезендә татар телен төп ике юнәлештә укыту күздә тотыла: «Туган тел» (туган телләре татар теле булган укучыларга татар телен өйрәтү) һәм «Дәүләт теле» (туган телләре татар теле булмаган укучыларга, ягъни татарлардан башкаларга татар телен өйрәтү).

1 нче таблица



«Туган тел» юнәлеше үз чиратында тагын икегә бүленә:

1) база өлеше (рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы татар балаларына туган телне (татар телен) өйрәтү);

2) тирәнтен өйрәнү өлеше (татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга туган телне өйрәтү).

Алдагы уку елында гомуми белем бирү оешмаларында туган телне укытуның эчтәлегенә караган үзгәрешләр көтелә. Беренчедән, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан эшләнгән уку планына тәңгәлләштереп, предметның исеме үзгәрә («Туган тел»). Икенчедән, яңа юнәлештә белем бирүдә төп игътибар коммуникатив компетенциягә, ягъни туган телдә дөрес, матур итеп сөйләшергә, логик эзлекле, иҗади, креатив рәвештә уйларга, мөстәкыйль эшләргә өйрәтүгә, әлеге процессны лингвистик (тел) һәм социомәдәни компетенцияләр белән бергә бәйләп алып баруга бирелә, ягъни компетенцияләр бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән, бер-берсен һәрдаим тулыландырып торырга тиеш.

Өченчедән, элеккеге кебек, рус мәктәбе, рус мәктәбенең татар төркемнәре, татар мәктәбе дигән бүленеш урынына дәүләт теле һәм туган тел (база өлеше, тирәнтен өйрәнү өлеше) дигән бүленеш кала. База өлеше (рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы татар балаларына туган телне (татар телен) өйрәтүне үз эченә ала. Тирәнтен өйрәнү өлеше дигәндә, татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга туган телне өйрәтү күздә тотыла.

Дүртенчедән, лексик темалар («Мин», «Тирә-як, көнкүреш», «Туган җирем», «Татар дөньясы») аша укучының иптәшләренә, гаиләсенә, әйләнә тирәгә, Туган иленә, татар дөньясына үз мөнәсәбәтен белдерә алуы, шулар ярдәмендә сөйләмне үстерү, тел байлыгын арттыру, туган телне өйрәтү күз уңында тотыла. [Шәкүрова, Гыйниятуллина, 2018, б. 5].

2 нче таблица

| **БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ** | | |
|---|---|---|
| **ЭЛЕККЕГЕ ВАРИАНТ** | **ЧАГЫШТЫРУ ЛИНИЯСЕ** | **ЯҢАРТЫЛГАН ВАРИАНТ** |
| *ТАТАР ТЕЛЕ* | **УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ИСЕМЕ** | *ТУГАН ТЕЛ<br>ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ* |
| *ЛИНГВИСТИК<br>КОММУНИКАТИВ<br>ЭТНОМӘДӘНИ* | **КОМПЕТЕНЦИЯЛӘР** | *КОММУНИКАТИВ<br>ЛИНГВИСТИК<br>СОЦИОМӘДӘНИ* |
| *РУС ТӨРКЕМЕ<br>ТАТАР ТӨРКЕМЕ<br>ТАТАР МӘКТӘБЕ* | **ДӘРӘҖӘ** | *ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ<br>БАЗА ӨЛЕШЕ<br>ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНҮ* |
| *Рус төркемнәрендә 12–17 лексик тема тәкъдим ителә; татар балалары белән эшләгәндә, лексик темалар күрсәтелми* | **ЛЕКСИК ТЕМАЛАР** | *«МИН»<br>«ТИРӘ-ЯК, КӨНКҮРЕШ»<br>«ТУГАН ҖИРЕМ»<br>«ТАТАР ДӨНЬЯСЫ»* |

«Туган тел»не өйрәнү барышы компетенцияләргә нигезләнә. Компетенция – латинчадан ирешү, тиешенчә ярашу, нигезләү мәгънәсен аңлата. «Туган тел»дән белем бирүнең максаты – Федераль дәүләт белем стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә, лексик темаларга нигезләп, укучыларда коммуникатив (аралашу осталыгы), лингвистик (тел), социомәдәни компетенцияләр булдыру.

Коммуникатив компетенция – укучыларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләренә караган ныклы күнекмәләр формалаштыруны күздә тота. Мәсәлән, сөйләм эшчәнлегенең (ягъни сөйләмиятнең) төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) аша укылган яки тыңланган текстның темасын, төп һәм өстәмә фикерен аңлау; текстны файдаланып, әңгәмә үткәрү, төрле стильгә һәм жанрга караган текстларны дөрес уку һәм аңлау; тәкъдим ителгән темалар буенча диалогик һәм монологик сөйләм оештыру (парлап эшләү); төрле чыганаклардан мәгълүмат туплау; сүзлекләрдән һәм электрон чаралардан дөрес файдалану; сөйләм этикеты нормаларын белү, аларны сөйләмдә дөрес куллану һ.б.

Лингвистик компетенция формалаштыру өчен тел гыйлеменең бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән барлык тармакларыннан (фонетика, графика, орфография, орфоэпия, лексикология, сүз төзелеше һәм ясалышы, морфология, синтаксис, пунктуация, стилистика һәм сөйләм культурасы) төп фәнни мәгълүматлар туплау һәм аларны сөйләмнең нигезенә салу сорала. Бу очракта билгеле бер контекст эчендә авазлар, интонация, сүзләрнең лексик һәм грамматик мәгънәләрен, ясалышын, җөмлә калыпларын, дөрес әйтелеш һәм язылыш кагыйдәләрен, тыныш билгеләрен һәм башкаларны бербөтен итеп системалаштырып бирү күздә тотыла. Димәк, тел гыйлеме бүлекләре, бер-берсе белән тыгыз бәйләнеп, гамәли яктан, ныклы сөйләм күнекмәләрен булдыру максатыннан өйрәтелә. Мәсәлән, әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен караганда, интонациягә, тыныш билгеләренә игътибар ителә, сүзләрнең контекстта чагылыш тапкан лексик мәгънәләре ачыклана, язылышы һәм дөрес әйтелеше искәртелә, кыен әйтелешле авазлар белән дә эшләргә туры килә. Кызганычка каршы, укыту барышында сөйләшү, аралашу, бала тарафыннан теге яки бу вакыйгага мөнәсәбәт белдерү кебек эш төрләре игътибардан читтә калып килде, нәтиҗәдә укучының туган теле белән кызыксынуы кимеде. Дәреслекләрдә лексик темаларның аз булуы (кагыйдәгә туры китереп, әдәби әсәрләрдән алынган җөмләләр белән эшләү) процессны катлауландырды гына.

Социомәдәни компетенциянең эчтәлеген укучыларның сөйләмен үстерү һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү, сөйләм калыбына нигезләп, язу осталыгын булдыру; телнең орфоэпик һәм интонацион нормаларын саклап, фикерне җиткерү; көндәлек аралашуга бәйле сөйләм этикеты үрнәкләреннән дөрес файдалану (сәүдә үзәкләрендә, күңел ачу паркларында, театрда,

музейда, концертлар залында, транспортта, урамда үзеңне тота белү (сәламләү, хушлаша белү, гафу үтенү, рәхмәт әйтә белү, сорау яки үтенеч белән мөрәҗәгать итү һ.б.); телнең милли мәдәниятне чагылдыру формасы булуын аңлату, тел чаралары, сөйләм репликалары ярдәмендә халыкның милли үзенчәлекләрен сурәтләү мөмкинлекләрен өйрәнү һ.б.) тәшкил итә [Гиниятуллина, Шакурова, 2018, б. 370].

Туган телне укытуның сыйфатын күтәрү, һәр сыйныфта аны эзлекле үзләштерү, сөйләмне дөрес төзеп, әдәби тел нормаларына туры китереп, телдән һәм язма рәвештә башкаларга җиткерә белү, туган телне өйрәнүнең нигезенә коммуникатив принципны салу бүгенге көн мәгариф системасы алдында торган мәсьәләләрнең иң мөһиме санала. Шуңа күрә «Туган тел» предметын укытуның эчтәлегенә караган төп яңалыкларның берсен белем бирү барышында коммуникатив компетенция формалаштыру тәшкил итә.

Аның өстенлекле якларыннан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

1) сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен тормышка ашырырга мөмкинлек бирә;

2) укучыларда телгә карата кызыксыну һәм сөйләшергә омтылыш уята;

3) телнең аваз системасы белән эшләргә һәрдаим юл күрсәтә;

4) лексик минимумны төгәл ачыклап, укучының сүз байлыгын арттыруына, яңа сүзләрне сөйләмгә кертүенә юнәлеш бирә [Шәкүрова, 2012, б. 27]

Коммуникатив компетенция, лингвистик һәм социомәдәни компетенцияләр белән тыгыз үрелеп, аларны һәрвакыт тулыландырып тора. Лексик материал фикернең эчтәлегенә бәйле рәвештә грамматик кагыйдәләр һәм сөйләм репликалары белән кертелә.




Югарыда бирелгән диаграммадан күренгәнчә, һәр дәрестә өйрәнелә торган материалның яртысыннан күбесе коммуникатив, калганының дүрттән өч өлеше (¾) лингвистик һәм дүрттән бере (¼) социомәдәни компетенция формалаштыруга юнәлтелгән булырга тиеш. [Шәкүрова, Гыйниятуллина, 2018, б. 9]

Һәр сыйныфта лексик материал үзара бәйләнгән дүрт блокка берләштереп бирелә: «Мин», «Тирә-як, көнкүреш», «Туган җирем», «Татар дөньясы».




Сөйләм телен үстерү максатыннан, беренче блок – «Мин» укучының үз мөнәсәбәтен белдерүгә юнәлтелгән лексик берәмлекләр белән эш итүен күздә тота: минем гаиләм (якын туганнарым), ерак кардәшләрем; туганнарны сәламләү, якын итә белү, алар белән аралаша белү;

туганлык серләрен сакларга өйрәтү; минем шөгылем; яраткан героем, яраткан язучым (шагыйрем), киләчәк көн һөнәрләренә карата минем мөнәсәбәтем һ.б.

Икенче блок – «Тирә-як, көнкүреш» дип атала. Биредә төп игътибар укучыларны кешелекле, иҗади, актив, мөстәкыйль, әйләнә-тирәне күзәтә, табигатьне саклый белә торган шәхес итеп тәрбияләүгә юнәлтелә. Йорт-җир, Туган як табигате, Интернет челтәрендә, социаль челтәрләрдә дөрес аралашу, Россия һәм чит ил югары уку йортлары, бүгенге көн модасы бәйле темалар тәкъдим ителә. Әлеге блок сөйләмне үстерүне, тел байлыгын арттыруны күз уңында тота һәм үз эченә һөнәрең белән кешеләрне куандыру, яраткан һөнәр сайлау, аның серләренә төшендерү, һөнәр сайларга өйрәтү кебек шәхси һәм коммуникатив универсаль уку гамәлләрен тормышка ашыруга ярдәм итә торган лексик темаларны ала.

Өченче блок – «Туган ил». Аның кысаларында татар халкы һәм Россия Федерациясе субъектлары халыкларының гореф-гадәтләре, традицияләре аша укучыларда гражданлык, патриотик хисләр, туган илгә карата хөрмәт, мәхәббәт уяту; Россия һәм чиктәш илләр, чит илләр белән мөнәсәбәтләр, Европа һәм Азия илләре, акча берәмлекләре, Туган илнең тарихи һәйкәлләре һәм истәлекле урыннары, чит илләрдә яшәүче татарлар, Туган илем – Россия буйлап сәяхәт итү һ.б. темаларны өйрәнү күздә тотыла.

Дүртенче блок – «Татар дөньясы». Биредә милли менталитет, фәлсәфә, үзаң, әхлак кануннары белән таныштыру, аерым алганда Сөембикә, Казан турында легендалар, татарлар һәм Россиядә яшәүче башка халыкларның милли һөнәрчелеге, татар әхлагы, татар халкының бизәнү әйберләре (беләзек, йөзек, балдак, алкалар һ.б.); татар зыялылары, татар театры тарихы, татар кино сәнгате, Идел буе халыкларының милли бәйрәмнәре («Сабантуй» (татар), «Каравон» (рус), «Гырон-быдтон» (удмурт), «Уяв» (чуваш), «Балтай» (мордва), «Семык» (мари), «Питрау» (керәшен), Татар халык уеннары, Татар кәсебе (кашыклар, чүлмәкләр ясау, итек басу, тегү, чигү, курай, гармун ясау һ.б.) кебек темаларны һәм алар белән бәйле сөйләм репликаларын өйрәнү күз уңында тотыла.

Мисал өчен 1 нче сыйныфта лексик теманың морфология, синтаксис бүлекләре белән үреп бирелеше алдагы слайдта тәкъдим ителә. «Татар дөньясы» блогы кысаларында өйрәнү өчен «Татар халык уеннары», «Җырлы биюле уеннар», «Башка халыкларның милли уеннары» кебек темалар бирергә мөмкин. Морфология һәм синтаксистан ике дәрәҗәгә (база өлешенә һәм тирәнтен өйрәнү өлешенә) аерып бирелгән теоретик материал коммуникатив һәм социомәдәни компетенцияләр җирлегендә формалаштырыла. *Кем? Нәрсә? Нинди? Ничә? Күпме? Кайда? Кая? Нишли?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр, җөмләдә сүз тәртибе, әйтү максаты буенча җөмлә төрләре сөйләмә һәм язма телне камилләштерүдә мөһим роль уйнарга тиеш.

3 таблица

| 1 нче сыйныф | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Тема | *Коммуникатив компетенция формалаштыру* | *Лингвистик компетенция формалаштыру* | | *Социомәдәни компетенция формалаштыру* |
| | | *База өлеше* | *Тирәнтен өйрәтү* | |
| Татар дөньясы | Татар халык уеннары («Буяу сатыш», «Яшерәм яулык», «Без-без, без идек», «Башмакчы», «Йөзек салыш»).<br><br>Җырлы биюле уеннар: «Түбәтәй», «Чума үрдәк, чума каз», «Ак калач».<br><br>Башка халыкларның милли уеннары «Змейка», «Салки» (рус халык уеннары).<br><br>«Бакыр бүкән» (башкорт халык уены).<br>«Йомышчы» (якут халык уены).<br><br>«Чур, все!» (тизәйткечләр белән качышлы уены) (коми халык уены) | *Кем? Нәрсә?* сорауларына җавап бирә торган сүзләрне татар һәм рус телләрендә чагыштыру. *Нинди?* соравына җавап бирә торган сүзләр. *Ничә? Күпме?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. *Кайда? Кая?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. *Нишли?* соравына җавап бирә торган сүзләр. Җөмләдә сүз тәртибе. | *Кем? Нәрсә?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр *Нинди? Кайсы?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. -рак/-рәк кушымчалары ярдәмендә предметларның билгеләрен чагыштыру. *Ничә? Ничәнче? Күпме?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. *Кайчан? Кайда? Кая?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. *Нишли? Нишләгән? Нишләде?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. | Сөйләм этикетының милли үзенчәлекләре: тыйнаклык, итагатьлелек, бер-береңә юл куя белү. Әңгәмәдәшеңә яхшы мөгамәләдә булу. Милли уеннар белән танышу. Уен этикеты. Яраткан уен, уенчыклар турында кыскача мәгълүмат бирергә өйрәтү. |

Туган телне өйрәнү барышында лексик, грамматик материалны кызыклы, тормыштан алынган вакыйгаларга таянып бирү укучыларның телне өйрәнү теләген арттыра гына, аның тормышта кирәклеген төшенергә ярдәм итә. Шуңа күрә дәресләрдә төрле ситуацияләргә корылган, сөйләм репликалары белән баетылган, аларны чишәргә ярдәм итә торган күнегү-биремнәр тәкъдим итү, шуларга нигезләнеп, укучыларның аралашу осталыгын үстерүгә игътибарны арттыру зарур.

Хәзерге көндә тирән мәгълүматлы, югары белемгә ия булу гына җитми, ә бәлки белемне функциональ яктан гамәли эшчәнлектә куллану осталыгына өйрәтә белү кирәк. Сөйләмдә сүз төркемнәрен, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, җөмләләр тезмәсенең төрле калыпларын куллану сөйләмне кыска, ачык, аңлаешлы итеп формалаштыра, кирәкмәгән кабатлаулардан коткара. Белем бирү эчтәлеген яңарту, перспективаларны билгеләү максатында лексик темаларны практикага кертү, ныклы коммуникатив, лингвистик һәм социомәдәни компетенцияләр формалаштыру укыту эшчәнлеген камилләштерергә ярдәм итәргә тиеш.

**Әдәбият**

*Гиниятуллина Л.М., Шакурова М.М.* Роль народной педагогики при развитии разговорной речи учащихся // Тюркский мир и исламская цивилизация: проблемы языка, литературы, истории и религии. Елабуга, 2018. С. 369–371.

*Шәкүрова М.М.* Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр). Казан: Ихлас, 2012. 144 б.

*Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М.* Башлангыч сыйныфларда «Туган тел» предметын укыту: яңартылган эчтәлек һәм перспективалар. Методик ярдәмлек. Казан, 2018. 40 б.

*Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М.* 5–9 нчы сыйныфларда «Туган тел» предметын яңача укыту. Методик ярдәмлек. Казан, 2018. 36 б.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Гиниятуллина Лилия Миңнулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*